■ Хәҙрәт вәгазе

# УКЫЙЫК, ФӘҺЕМ АЛАЙЫК!

### Кемгә надан дип әйтелә?

Рагыйб әл-Исфәхани надан мәгънәсенә килә торган "җәһл" сүзен өч төрле ачыклый.

Беренчесе, нәфеснең белемсез булуы; икенчесе, чын хакыйкатьтән башка бер нәрсәгә ышану; өченчесе, бер мәсьәләдә эшләнергә тиеш булган нәрсәнең киресенчәсен эшләү.

Надан дип белемнән мәхрүм булган, җитди хәрәкәт кыла алмаган һәм үзен танымаган кешеләргә әйтелә. Ислам диненнән алда булган заманга җаһилият дип әйтелә, һәм җаһили хәрәкәтләр һәр дәвердә һәм бөтен җирдә күренергә мөмкин. Хз. Билалга "кара хатынның улы" дип әйтү белән кимсеткән Хз. Әбү Зәрргә пәйгамбәр Әфәндебез (с.г.в.) шулай диде: "Аны әнисенең төсе аркасында хурлыйсыңмы? Димәк, синдә җаһилият әхлагыннан бер өлеш әле дә бар". (Бохари, иман, 22) Янә Аллаһның Рәсүле (с.г.в.): "Җаһилият дәгъвасын дәвам иттерүчеләр бездән түгел", - дип әйтә. (Мөслим). Башка бер хәдистә шулай ди: "Өммәтем арасында җаһилият дәвереннән калган һәм бөтен яклап ташлый алмаячак дүрт нәрсәләре бар: нәселлек белән мактану, башкаларның нәсел-нәсел юлларына тел сузу, йолдызлар сәбәпле яңгыр сорау, вафат булган кеше өчен кычкырып елау". (Мөслим. җеназа, 9).

### Кешеләргә рәхмәт әйтмәгән, Аллаһка да шөкер итмәс

Рәсүлүллаһ (с.г.в.) менбәргә менеп шулай әйтте: "Аз булганга шөкер кылмаган, күпкә дә шөкер кылмас. Кешеләргә рәхмәт әйтмәгән, Аллаһка да шөкер кылмас. Аллаһның нигъмәтләрен сөйләү - шөкер, аларны искә алмау - нанкөрлек (көферлек кылу). "Бердәм булу - рәхмәткә, аерылу - газапка сәбәпче булыр". Ногман бин Бәшер (р.г)нең бу риваятендә рави Әбү Үмамә Әл-Баһили шулай әйтте: "Сәвады Әгъзамнан (күплек халыктан) аерылмагыз". Шул вакыт бер кеше:

- Сәвады Әгъзам нәрсә ул, - дип сорады.

- "Нур" сүрәсендәге шул аятьнең мәгънәсеннән аңлашылган нәрсә, - диде, - "Әйт: Аллаһка итәгать кылыгыз, пәйгамбәренә итәгать кылыгыз. Әгәр баш тартып борылсагыз, (пәйгамбәрнең) вазифасы тик тәблигъ итү генә. Сезнең "вазифагыз" итәгать кылу. Әгәр аңа итәгать кылсагыз, туры юлны табарсыз. Пәйгамбәрнең вазифасы ачык итеп тәблигъ итүдән башка түгел". (Нур, 54).

Әбү Зәррел Гыйфари (р.г.) шулай әйтә: "Рәсүлүллаһны тыңладым, халыкка сөйли иде: "И Дауд нәселе! Сез Аллаһка шөкер кылу өчен тырышыгыз. Колларым арасында кирәк рәвештә шөкер кылучылар аз" (Сәбә, 13) мәгънәсендәге бу аятьне укып шулай диде:

"Кемгә өч нәрсә бирелгән булса, Дауд пәйгамбәргә бирелгәннәр шулай ук аңа да бирелгән булыр.

1. Яшерен һәм ачык бөтен урында Аллаһтан курку.

2. Кызып киткән вакытта һәм куанычта булганда гаделлектән аерылмау.

3. Фәкыйрьлек һәм байлык хәлләрендә сакчыл булу".

### Бурычка бирү

Әнәс бин Малик (р.г.) аңлата: Рәсүлүллаһ (с.г.в.) шулай диде: "Мигъраҗ кичәсендә җәннәт капкасы өстендә шул сүзнең язылганын күрдем:"Садака биргән кешегә биргән садакаларының ун каты белән әҗер биреләчәк. Ә бурычка акча бирүчеләргә ун сигез каты белән әҗер биреләчәк". Мин: "И Җәбраил! Бурычка бирелгән нәрсә ни сәбәпле садакадан өстенрәк?" - дип сорадым. Ул: "Чөнки сорап йөрүчеләр күп вакытлар яннарында акча булган хәлдә садака сорап йөрерләр. Ләкин бурычка акча сораган кеше мохтаҗ булганы аркасында кешедән акча сорар", - диде.

### Аллаһ (җ.җ.) дога кылучыга бирер

Халык арасында өч айлар дип беленгән рәҗәп, шәгъбан һәм рамазан айлары бик фазыйләтле айлар. Чөнки бу айларның эчендә дога кылу өчен аерым кичләр билгеләнгән. Бу өч ай арасында, унбер айның солтаны, дип аталган рамазан ае иң фазыйләтлесе. Чөнки бу айда Корьән Кәрим инә башлады һәм бер ай буена ураза тоту фарыз ителде.

Рамазан сүзе "кызу таш" мәгънәсенә килә торган "рамиз" тамырыннан алынган. Рамазан ае бик эссе көннәргә туры килгән өчен, аңа бу исем бирелгән. Аерым буларак, ничек кызу таш үзенең тирәсендә булган нәрсәләрне эретеп юкка чыгара, рамазан да кешеләрнең гөнаһларын яндырып берегәне өчен аңа бу исем бирелде, дип әйтүчеләр дә бар. Кайберләренчә, рамазан сүзе "ява торган яңгыр" мәгънәсенә килә торган "рамиз" сүзеннән алынган булып, яңгыр яуган вакытта ничек җир йөзен пычраклардан пакьли, шулай ук рамазанның да кешеләрне гөнаһлардан пакьләгәне аркасында бу исемнең бирелгәне риваять ителә.

Корьән Кәрим төшә башлаган бу айда, Кадер сүрәсендә әйтелгән кебек, мең айдан да хәерлерәк Кадер кичәсе бар. Иң башта Кадер кичәсе, аннан Бәрагать кичәсе, Рәгаиб кичәсе һәм Мигъраҗ кичәсе Аллаһу Тәгалә тарафыннан мөэмин бәндәләргә бүләк ителгән бөек кичләрдер.

### Гыйбадәт - кол булуның серенә ирешү

Гыйбадәт - кешенең барлыгы, тормышы, аңлавы һәм иманы кебек нигъмәтләр каршында Аллаһның биргән бу нигъмәтләренә "хәл теле" белән шөкер кылуның исеме. Гыйбадәтсезлек, көферлек булмаса да, нигъмәтләрнең кадерен белә алмау һәм аларны бирүчегә хөрмәтсезлек.

Гыйбадәт иман аркасында дөнья һәм ахирәт сәгадәтен казану өчен безгә Раббыбыз тарафыннан бирелгән бер очрашу юлы һәм әдәбе. Бу юлны таба алмаганнарның, бу әдәпкә ирешә алмаганнарның хак белән очрашулары да мөмкин түгел.

Гомерләрен хакыйкать урынына әүлияларның кәрамәтләрен аңлату белән узыдырып тынычлванучы кайбер чын хакыйкатьләргә ябык рухлар, тормышларның азагына кадәр бу аңлатмаларның тәэсире белән яшәгән булсалар да, үзләренең булган дәрәҗәләреннән аз гына да алга китә алмаслар.

Гыйбадәт - кешедәге яхшылык, матурлык һәvм дөреслек уйларына куәт бирә торган бер чыганак, һәм нәфеснең начар якларын төзәлтү белән аны фәрештәләр галәменә күтәрә торган серле бер хакыйкать. Һәр көнне бер ничә мәртәбә бу чаганакка мөрәҗәгать иткән рух инсаны камил булу юлына кергән булыр. Бу юлга кергәннән соң нәфес ягыннан килү ихтималы булган һәр төрле һөҗүм каршында үзен саклар өчен кирәк булган нәрсәсен тапкан, димәк.

Гыйбадәтнең иң фазыйләтлесе Аллаһу Тәгаләне белеп, Аны ярату һәм кешеләргә файдалы булу. Бу мәсьәләдә иң өстен дәрәҗә - эшләгән бөтен эшләрдә Аның ризалыгын эзләү.

### Нәрсә ул гамәл?

Бер мөселманның ышануының нәтиҗәсе буларак кылган һәртөрле гыйбадәтләре гамәл дип атала. Кешенең ният кылганнан соң акылы белән аңлап эшләгән бөтен хәрәкәтләренә дә гамәл диелә. Корьән Кәримнең бик күп урыннарында иман белән гамәл янәшә аңлатылган. шулай булгач кешенең котылуы иң башта иман, шуннан соң гамәлгә таянганы чын хакыйкать.

### Сөйләнгән хәбәрләрнең дөреслеген тикшерегез

"И иман китергән бәдәләр! Әгәр фасикъ кеше сезгә хәбәр китерсә, ул хәбәрнең хакмы, юкмы икәнлеген тикшерегез. Юкса, абайламастан, бер төркем халыкка зыян китерегез дә, соңыннан үкенерсез" (Хөҗүрәт, 6). Сөйләнгән сүзгә шундук алданып, хәбәрне тикшермичә, тизрәк ачуланмагыз. Тикшерегез, аңлагыз һәм тыңлагыз. Чөнки гөнаһ эләүдән курыкмаган кеше, ялган сүз әйтүдән дә курыкмас. Фәхретдин әр-Рази: "Бу сүрәдә мөэминнәрнең әхлагы иң яхшыга юнәлдерү бар", - дип әйтә.

> Раббың болай боерды:
>
> "Аллаһтан башка беркемгә дә табынма. Әти-әниеңә изгелек кыл".
>
> "Аларга булышырга, хезмәт итәргә авырсынма".
>
> "Әгәр берәрсе яки икесе дә синең янда картлыкка ирешсәләр, син аларга "уф!" та димә, кәефләрен җибәрмә, йомшак һәм ягымлы сүзләр генә сөйлә".
>
> "Әти-әниеңә шәфкатьле һәм мәрхәмәтле бул".
>
> "Алар өчен шушы доганы кыл: "Я Раббым! Алар мине кечкенә чагымда үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыл! Әмин".
>
> *(Корьән Кәрим, "Исра" сүрәсе, 23-24-че аятьләр)*

### Замана түгел, кешеләр бозылды

Кешеләр очрашкан бәлаләр аркасында һәрвакыт заманны гаепле күрәләр. Хәтта шундый дәрәҗәдә ки, заманны бәхетсезлекнең анасы, дип белүчеләр дә аз түгел. Дөресендә, "заман бозылды, фетнә-фәсат бар, дип әйтәләр. Заман бозылмады үзләре фетнә-фәсат" шигырендә әйтелгән кебек, фетнә-фәсат заманда түгел, кешеләрнең үзләрендә. Чөнки, чыннап та, гасырның, заманның гаебе, кабахәте һәм зарары юк. Ул кадерле бер нигъмәт. Заманның кадерен белеп тә, хәер юлында тырышмаганнар зыяндадыр. Бу мәсьәлә белән бәйләнешле буларак Аллаһның Рәсүле (с.г.в.): "Заманны сүкмәгез. Чөнки заман минем гаинәи изафиям (Көзгедәге чагылы-шым)", - дип әйткән. (Әхмәт бин Хәнбәл).

### Иң сөекле бәндә кем?

Хз. Муса (г.с.) беркөнне дога кылган вакытта: "И Раббым! Колларыңның арасында сиңа иң сөйкемле кем, миңа күрсәт", - дип сораган иде. Аллаһу Тәгалә шулай җавап бирде: "И Муса! Колларым арасында миңа иң сөйкемле булганы - мөэмин кардәшенең аягына бер чәнечке кадалганын ишеткән вакытта, үзенең аягына кадалган кебек кайгырып сызланучы кеше".

### "Мин туры юлга кереп киттем" дигән хисләр бик хаталы

Бер бендәнең: "Мин туры юлга кереп киттем", дигән хисләре һәм хәрәкәтләре, гүяки бервакыттан соң Аллаһка мохтаҗ түгел мәгънәсенә килә. Шайтанның уң яктан килүе дигән мәгнәгә килә торган бу хисләр һичбер вакытта мөэмин кешедә булырга тиеш түгел (шайтан кешегә сул яктан килү белән тәэсир итә алмаган булса, мондый вәсвәсәләр белән аны җиңәргә тырышыр, күп вакытларда максатына ирешер).

Мондый хисләргә ия кешедә илхад, ягъни ышану бозыклыгы бар димәк.

Дөреслектә бөтен нәрсә һәрвакыт Аңа мохтаҗ. Кеше еллар буена гыйбадәт кылган булса да, бөтен бу гыйбадәтләр аның рухында бөтенләй туры юлны табуга җитмәскә мөмкин. Шуның өчен бөтен хәл һәм хәрәкәтләребездә Аллаһу Тәгаләгә сыенып, Аннан ихлас һәм истикамәт (туры юлдан тайпылмауны) сорарга тиешбез.

### Һәр кеше үзенең утын үзе китерә

Габбасиларның мәшһүр хәлифәсе булган Һарун Рәшид вакытында яшәгән Бәһлүл Данә (VIII йөз) шул дәвернең иң мәшһүр әүлияләреннән берсе иде. Кайбер вакытларда, максатлы буларак сорау бирүче кешеләргә аларның дәрәҗәләренә карата җаваплар биргән өчен, халык аны "тиле" дип саный иде. Ләкин ул, киресенчә, бик акыллы булып, хикмәт белән хәрәкәт кыла иде.

Бәһлүл Данә һәрвакыт Һарун Рәшиднең якын тирсендә йөреп, әгәр аның хаталарын күрсә, кирәк рәвештә кисәтү ясый иде.

Беркөнне Һарун Рәшиднең хозурына киемнәре тузанлы һәм пычрак хәлдә килеп керде. Араларында шундый сөйләшү булды:

- Бәһлүл, бу нинди хәл, кайдан киләсең,

- Җәһәннәмнән киләм, и хөкемдар.

- Нәрсә эшләдең җәһәннәмдә,

- Ут кирәк булды да, шуның өчен анда бардым.

- Китерә алдыңмы соң,

- Юк, әфәндем, китерә алмадым.

Җәһәннәмнең сакчы фәрештәләре белән көрештем, алар миңа: "Сез уйлаган кебек ут монда юк, бөтен кеше үзенең утын дөньядан китерә", - диделәр", - дип җавап биргән.

Йөрәкнең ялтыраткычы - тәүбә

### Әбү Һурайра (р.г.) аңлата

Хз. Пәйгамбәр (с.г.с.) шулай диде: "Кеше бер хата ясаган вакытта, йөрәгендә кара бер эз барлыкка килер. Әгәр кеше ул хатадан ераклашып, (Аллаһу Тәгаләдән) гафу сорап тәүбә кылган булса, йөрәге ялтыратылыр (пычрак эз юылыр). Әгәр шул ук гөнаһны эшләргә дәвам итсә, йөрәгендәге эз тагы да күбәйтелер. Хәтта шундый бер вакыт килеп җитәр ки, йөрәге кап-кара булыр. Менә бу эз Аллаһу Тәгаләнең: "Юк, аларның эшләп торган яман гамәлләре йөрәкләрен күгәртте" (Мутаффифин, 14) аятендәге күгәрү мәгънәсен аңлата.

**"Гаиләм" журналынан алынды.**